ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЮГАРЫ ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Ул. Чехов, д.54, с. Верхний Услон, 422570

Чехов ур., 54 нче йорт, Югары Ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

02.04.2024 с. Верхний Услон № 1

Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлегенең Киров исемендәге авылында гражданнар җыенының 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү 22.11.2013 ел № 90 тәртибенең 2 пункты (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлегенең Киров исемендәге авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023нче елның 17нче ноябреннән 1 нче номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 13 апреленә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне раслрага:
«Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлегенең Киров исемендәге поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы булырсызмы:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Киров мәдәният йортында гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: РФ, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Киров ис. поселок, Үзәк ур., 15 йорт, 10 сәгатьтә.

4. Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге Башлыгы М. Г. Зыятдинов